ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06 02 2023 г. № 104

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенең кече командалык итү составы хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 2 өлешенең 7 пунктчасы, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенең кече командалык итү составы вазыйфаларында хезмәт узучы һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган Россия Федерациясе гражданнарына социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенең кече командалык итү составы вазыйфаларында хезмәт узучы һәм башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган гражданнарны туклану буенча ата-ана взносларын түләүдән азат итәргә.

2. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә (Логинова С.Н.) Түбән Кама муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән балалар белем ала торган Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) билгеләнгән үрнәктәге хезмәт таныклыгы күчермәсе һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе хезмәткәре эш урынынннан белешмә белән бушлай кайнар туклану бирү турында гаризалар кабул итү буенча эш оештырырга;

2) укучыларның туклануын оештыруны тәэмин итәргә;

3) гражданнарның махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы балалары югарыда күрсәтелгән категорияләрне алган очракта, укучыларга азык-төлек җыелмалары бирүне оештырырга,

4) Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе кече командалык итү составы хезмәткәрләре балалары санының даими мониторингын алып барырга.

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә (Гарифуллин А.Х.) әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чараларын тиешенчә гамәлгә ашыруны тикшереп торырга.

5. Әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасы Россия Федерациясе гражданы тарафыннан Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенең кече командалык итү составы вазыйфасында хезмәт узу чорына билгеләнә дип билгеләргә.

6. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

7. Әлеге карар 2023 елның 1 февралендә үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН МКУ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874